# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

17 03 2025 ел № 811

«Тукай муниципаль районы заказчылары ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү буенча функцияләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган турында» 2019 елның 11 ноябрендәге 36/6 номерлы Тукай муниципаль районы Советы карарын гамәлгә ашыру хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 1 декабрендәге 3730 карарына үзгәрешләр кертү турында

2024 елның 26 декабрендәге 484-ФЗ номерлы Федераль закон, 2024 елның 29 маендагы 124-ФЗ номерлы Федераль закон, Тукай муниципаль районы уставы нигезендә Башкарма комитет

КАРАР БИРӘ:

1. «Тукай муниципаль районы заказчылары ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү буенча функцияләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган турында» 2019 елның 11 ноябрендәге 36/6 номерлы Тукай муниципаль районы Советы карарын гамәлгә ашыру хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 1 декабрендәге 3730 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 өлешнең 1.2 пункты 1.2.2 һәм 1.2.3 пунктчаларында «граждан-хокукый шартнамә» сүзләре алдыннан «язма рәвештә төзелгән һәм» сүзләрен өстәргә;

1.2. 1 нче кушымтаның 1 өлеше 1.2 пункты 1.2.3 пунктчасында «15 статьясы 4, 4_1, 4_3 һәм 5» сүзләрен «15 статьясы 4, 4_3 һәм 4_4» сүзләренә алыштырырга;

1.3. 1 нче кушымтаның 1.2 пункты 1.2.1 пунктчасы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«заказчы - дәүләт яки муниципаль заказчы яисә әлеге Федераль законның 15 статьясы 1, 2_1, 4, 4_3 һәм 4_4 өлешләре нигезендә сатып алуларны гамәлгә

ашыручы бюджет яки автоном учреждение, дәүләт яки муниципаль унитар предприятие яисә башка юридик зат.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), рәсми сайтта (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе К.Р. Нәҗмиев